Республика Татарстан
**ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423950, п.г.т.Уруссу ул.Пушкина, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

Татарстан Республикасы
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**
423950, Урыссу ш.т.б. Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

“11” 11 2019ел № 79

Белем бирү учреждениеләрендә эшләүче
яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган
күтәрү пособиесен түләү һәм аны кире кайтару
тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләренең яшь белгечләрен мәгариф һәм педагогик потенциалны үстерү системасына җәлеп итү, матди ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ Федераль закон, «Мәгариф турында» 22.07.2013 ел, № 68-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Уставына таянып, карар бирәм:

1. Кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы белем бирү учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган пособие түләү һәм аны кире кайтару тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карар 2019 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.
3. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУга әлеге карарны үз ведомство буйсынуындагы барлык муниципаль мәгариф учреждениеләре игътибарына җиткерергә.
4. Карар кул куелган көннән үз көченә керә һәм районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгына йөкләргә.

Район башлыгы урынбасары вазыйфаларын башкаручы С. Р. Төхбәтуллин

Р. М. Якупов
2-74-14

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы урынбасары
вазифаларын башкаручы
Карарына Кушымта
« 11 » 11 2019 ел № 79

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы белем бирү учреждениеләрендә эшләүче
яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган
яңа урынга бару пособиесен түләү һәм аны кире кайтару
тәртибе

1. Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ Федераль закон, «Мәгариф турында» 22.07.2013 ел, № 68-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган пособиене (алга таба – яңа урынга бару акчасы) билгеләү, түләү һәм кире кайтару тәртибен билгели.

Яшь белгеч дип әлеге Нигезләмә максатларында 35 яшьтән өлкән булмаган, дәүләт югары һөнәри яки урта һөнәри белем бирү учреждениесенең көндезге бүлекчәсен тәмамлаган һәм уку йортын тәмамлаганнан соң Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениесе белән өч ел дәвамында (алга таба - яшь белгеч) өч ел срокка хезмәт килешүе төзегән педагог хезмәткәре таныла.

2. Яңа урынга бару пособиесе түләнә:

2.1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениесе белән беренче тапкыр кимендә өч ел срокка

хезмәт килешүе төзегән яшь белгечләргә. Яшь белгечнең белем бирү учреждениесендәге бурычлары әлеге вакыт эчендә өстәмә шарт сыйфатында хезмәт килешүендә карала;

2.2. Уку йортын тәмамлаганнан соң, педагогик белгечлек буенча өч ел дәвамында соңгы эш урыны буенча эшләүче яшь белгечләргә, әгәр элекке эш урыны буенча мондый матди ярдәм күрсәтелмәсә.

3. Яңа эш урынына бару пособиесен түләү һәм кире кайтару тәртибе:

3.1. Уку йөкләнешенә карамастан, яшь белгечләргә, район коэффициентын кертмичә, бер тапкыр 30000 сум күләмендә пособие түләнә;

3.2. Яшь белгечнең белем бирү учреждениесендәге эш йөкләмәләре, яңа эш урынына бару пособиесен алганнан соң, билгеләнгән вакыт эчендә, өстәмә шарт буларак, хезмәт килешүендә карала. Бу чорда яшь белгечнең бала карау буенча отпускта булу вакыты исәпкә алынмый;

3.3. Яшь белгеч яңа эш урынына бару пособиесен алу өчен, бер ай эш тәмамланганнан соң, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениесе җитәкчесе исеменә шәхси гариза җибәрә. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының белем бирү учреждениесе җитәкчесе яшь белгеч белән язма рәвештә яңа эш урынына бару пособиесен түләү турында килешү төзи (Кушымта №1);

3.4. Муниципаль белем бирү учреждениесе җитәкчесе муниципаль белем бирү учреждениесенә бухгалтер хезмәте күрсәтүче «Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль бюджет учреждениесенә яңа эш урынына бару пособиесе исәпләү һәм түләү өчен яшь белгечнең белеме турындагы документның, хезмәт кенәгәсенең, хезмәт килешүенең, яңа эш урынына бару пособиесен түләү турында шартнамә күчермәләрен, элекке эш урыннарыннан моңа кадәр яңа эш урынына бару пособиесе түләнмәве турында белешмәләр белән белем бирү учреждениесе җитәкчесе боерыгын җибәрә.

3.5. Яңа эш урынына бару пособиесен түләү документлар пакетын тапшырганнан соң бер ай эчендә муниципаль белем бирү учреждениесенә бухгалтер хезмәте күрсәтүче Татарстан Республикасы «Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МБУ тарафыннан башкарыла;

3.6. Яшь белгеч Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының бер муниципаль белем бирү учреждениесеннән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының башка муниципаль белем бирү учреждениесенә күчерү тәртибендә эштән киткәндә яңа эш урынына бару пособиесе кире кайтарылырга тиеш түгел;

3.7. Муниципаль мәгариф учреждениесе белән хезмәт килешүе өзелгән очракта, хезмәткәр инициативасы буенча өч елга кадәр (якларның ихтыярына бәйсез рәвештә хезмәт килешүен өзү очракларыннан тыш) хезмәткәр мәгариф учреждениесенә түләнгән яңа эш урынына бару пособиесе суммасын тулы күләмдә түли, бу исә хезмәт килешүендә өстәмә шарт буларак карала;

3.8. Яңа эш урынына бару пособиесе суммасын кире кайтару “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе” муниципаль бюджет учреждениесе муниципаль белем бирү учреждениесенә бухгалтер хезмәте күрсәтүче кассасы аша муниципаль мәгариф учреждениесе җитәкчесе боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Билгеләнгән тәртипне үтәү, яңа эш урынына бару пособиесен түләүгә бүлеп бирелгән бюджет акчаларын максатчан файдалану өчен җаваплылык муниципаль мәгариф учреждениесе җитәкчесенә йөкләнә.

Кушымта
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
муниципаль белем бирү учреждениеләрендә
эшләүче яшь белгечләргә яңа эш
урынына бару пособиесен
түләү һәм аны кире кайтару тәртибе
турында Нигезләмәгә

**Бер тапкыр түләнелә торган яңа эш урынына бару пособиесен түләү турында КИЛЕШҮ**

_______________________ «____»___________20___ел
(торак пункт исеме)

_____________________________________________________________________
______________________________________(мәгариф учреждениесенең
исеме)_______________________________
(мәгариф учреждениесе вазифаи затының вазифасы, Ф.И.А.и
күрсәтелә)
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы карары һәм Устав нигезендә эш итүче, алга таба Яклар дип аталачак
_____________________________________________________________ йөзендә

_____________________________________________________________________
беләән , (мәгариф учреждениесе хезмәткәренең Ф. И. А.и тулысынча)
«____»________ 2019 елда № _____ Килешүне түбәндәгеләр турында
төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

1.1. ______________________________________
(мәгариф учреждениесе хезмәткәренең Ф.И. А.и. тулысынча)
_____________________________________________________________________
шәхси гаризасы нигезендә

_____________________________________________________________________
_________________________________________________________
(мәгариф учреждениесенең исеме)
________________________________________________
(мәгариф учреждениесе хезмәткәренең Ф. и. а.и.
тулысынча)
бер тапкыр бирелә торган яңа эш урынына бару пособиесен 30 000 (утыз мең) сум 00 тиен күләмендә түли.
1.2.__________________________________________________________________
( мәгариф учреждениесе хезмәткәренең Ф. И. А.и. тулысынча)
_________________________________________________________,

(мәгариф учреждениесенең исеме)

кимендә өч ел дәвамында эшләвен дәвам итәргә вәгъдә бирә
(эш чорында бала карау буенча отпускта булу вакыты саналмый).

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

Килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән суммада
___________________________________________________________________
_________________( мәгариф учреждениесенең исеме)
бер тапкыр бирелә торган яңа эш урынына урнашу пособие түләргә вәгъдә бирә
_______________________
___________________________________________________________________________
__

_______________________________________________________________________
(мәгариф учреждениесенең исеме)

___________________________________________________________________________
__, __________________________________________________________________
(мәгариф учреждениесе хезмәткәренең Ф. и. а.и. тулысынча)_
вакытыннан алда эштән киткән очракта, бер тапкыр бирелә торган пособие суммасын тулы күләмдә кайтаруны таләп итәргә хокуклы (якларның ихтыярыннан бәйсез хәлләр буенча хезмәт килешүен өзү очракларыннан тыш).___________________________________________________________________________
_______
(тулысынча мәгариф учреждениесе хезмәткәренең Ф. И.А.и.)
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениесеннән
2.3. _________________________________________________________________________
(тулысынча мәгариф учреждениесе хезмәткәренең Ф.И.А.и.)
вәгъдә бирә:
2.3.1. Хезмәт килешүе төзелгәннән соң кимендә 3 елдан ким булмаган чорда (эш чорында бала карау буенча отпускта булу саналмый) ________________(мәгариф учреждениесенең исеме)
.
эшен дәвам итәргә .
2.3.2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениесе белән хезмәт килешүе вакытыннан алда өзелгән очракта (якларның ихтыярына бәйсез шартлар буенча хезмәт килешүен өзү очракларыннан тыш), яңа эш урынына урнашу пособиесенең тулы күләмен түләргә.

## 3. Килешүнең гамәлдә булу срогы

3.1. Әлеге Килешү яклар кул куйган вакыттан үз көченә керә һәм һәр якның йөкләмәләрен үтәүгә кадәр гамәлдә була.

## 4. Башка шартлар

4.1. Әлеге Килешү бер үк төрле юридик көчкә ия ике нөсхәдә, якларның һәркайсы өчен бер нөсхәдә төзелде.
4.2. Әлеге килешү шартларын үтәгәндә яклар арасындагы каршылыклар һәм бәхәсләр гамәлдәге законнар нигезендә хәл ителә.